Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

Чаян



7

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ ИЮЛЬ * 2024 * КАЗАН

Сергей КОКАРЕВ



Алмаз ХӘМЗИН

ШИК

Гел шикләнеп яшим хәзер...
Нәрсәдән?..
Көн дә, төн дә бер төслерәк –
Йокы юк...
Кинәт юкка чыгармын күк,
Килсәләр...
Гел тәрттереп сөйләшәм бит,
Атып ук.

Атам, кадыйм һәм тәнкыйтьлим
Барчасын.
Бигрәк тә каты эләгә
Байларга.
Эшләп түгел, талап җыйган
Акчасын
Белмәгәнгә күрә кая
Куярга...

Куңелләргә борчу салган
Чор килде.
Тигезлектә яшәмәүгә
Зар тулды.
Хыялларда йөргән хисләр
Күмелде.
Ялгышларны аңлатучы –
Юк булды.

Әнә, кара, ни кылана
Түрәләр?..
Иң акыллылар югыйсә
Анда гел!..
Баксаң ришвәткә батканнар –
Беләләр.
Халык күрә илдә түгел –
Ал да гөл...

Сайланганнар сайлый һаман
Рәхәтне.
Үзләренә җитми – тыймый
Нәфесен.
Кануннарын яза яклап
Бәхетен.
Һәм кул чаба, сыйпап
Буксәсен.

Шиккә баткан җаннар күзе
Ишектә.
Колаклары кәтә тәрәз
Шакыйсын...
Йөрәк җәфасына төшәр
Соң чиктә
Җитәр хәлгә килдем, Аллам
Сакласын!

Тел төбемдә бүтән нәрсә –
Аңлагыз!
Фикеремнең төп максаты –
Башкача.
Ил тулы гел ахмаклар түгел –
Санагыз!
Без яшәргә тиештер бит
Яңача!

Валерий ТАРАСЕНКО



Максим СМАГИН





ШОМБАЙ болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Безнең йорт төзүчеләр, табыш артыннан куып, бөтенләй кешелек сыйфатларын җуйганнар, ахрысы. Безнең шәһәрдә Орлов зираты белән янәшәдә күп катлы йорт төзи башладылар. Югыйсә санитар нормалар буенча зона 500 метр тәшкил итәргә тиеш бит. Өстәвенә әле, оялмыйча, «зират фатирларына» парк янындагы торак дип реклама ясыйлар...

К. ИВАНОВА

ЧАЛЛЫ

– Минемчә, алар рекламаларына күп нәрсәләрне кертергә онытканнар: яшел зона, тыныч күршеләр, вафат булганнарны катафалк ялламыйча гына, подъездан турыдан-туры җирләү мөмкинлеге турында искә алмаганнар, – диде Шомбай ага, укучыбызның хаты белән танышкач.

Михаил МИХАЙЛОВ

“БЕЗ БУЛДЫРАБЫЗ!”НЫ ЧЫН БУЛДЫРУ

Компаниянең уңышлы үсеше, гадәттә, хезмәткәрләрне ышандырырлык дәлилләргә таянып үсендерү – коллектив бик уңай караштa.

Премия вәгъдә итеп түли алмасаң – син такылдык!

Аз күләмдә премия түләвең – хезмәткәрләреңдә гомерлек мыскыллы хатирәләр калдыра!

Премияңне азайтып түләсәң, болай килеп чыга – син саран!

Керәгеннән күбрәк түләп ташласаң, киресенчә – акчаның бер өлешен җилгә очырган кебек була!

Премияне ел ахырында түләсәң – әйтерләр: ешрак түләргә була иде түгелме соң!

Ай саен түләп барсаң – әйтерләр: сирәк, ләкин күбрәк күренә!

Премияне үзеңнән башка барысына да түләсәң – демократия уйнап куясың!

Үзеңә генә премия язсаң – хәзерге заман җитәкчеләренең сыйфатларын файдаланасың!

Кайберәүләргә генә сайлап түләсәң – коллективны талаштырасың!


Ялкауга премия билгелисең – тырышларны мыскыллыйсың!

Премияне һәрберенә заманча итеп, банк карточкасына күчерәсең – мырлап йөрүчеләр күбәя: элек җайлы иде, ведомостька кул куеп кына алышлы, кемнең күпме алганын да күрәсең!

Шунысына игътибар бирү кирәк: Аллага ышанучылар гына түгел, кайбер заман кешеләре дә төгәл белә: премия – күктән бирелә!

Әмма теләсә нинди югарылыктагы җитәкчегә тиешле, төгәл, вакытында һәм дөрес премия түләү мөмкинчелеген табу – ул компаниянең уңышлы үсешенә йогынты ясау гына түгел, коллектив тарафыннан ихлас бәя алу да – перспективага юл яру, ягъни “Без булдырабыз!..”

Вячеслав ШИЛОВ



* * *

Фирманың генераль директоры яшь хезмәткәрне кабинетына чакырта:

– Мин сезне чын күңелемнән тәбрик итәм! Сез күзгә күренеп үсәсез. Әле алты ай элек кенә сез гади сатучы идегез. Эшли башлавыгызга бер ел үтүгә, секция мөдире булдыгыз. Тагын өч айдан – директор урынбасары. Ә бүген мин сезне кибет директоры итеп билгелим. Йә, моңа нәрсә әйтерсез?

– Рәхмәт сиңа, әти!

Игорь КИЙКО



Хәвефле ләззәт

Билгеле булганча, зарарлы гадәтләр – ләззәт алуның иң тиз һәм гади ысулы. Бу турыдан-туры наркоманнар һәм аларга хезмәт күрсәтүче "эшмәкәр"ләргә бәйләнгән. Зарарлы гадәт ияләренең күңелен күрү максаты белән соңгылары тыелган матдәләр җитештерү өчен чып-чын цехлар оештыралар. Берәүләре ул матдәләрне кулланып ләззәт алуга бирелгәндә, икенчеләре аларны ясап һәм китереп торалар.

Күптән түгел Казанда нарколаборатория өстенә чыкканнар. Оештыручысы аның өчен йорт алган, җиһазлар, химик компонентлар сатып алып, "халык кулланышы товарлары" куа башлаган. Инде табыш көтә башлаганда, аның эзенә махсус органнар төшкән.

Ә Кайбыч районында охшаш "проект" уңышлырак эш иткән – анда 14 килограмм синтетик наркотик "пешерергә" өлгергәннәр. Өч "лаборант"ны эш урынында эләктергәннәр. Тикшерүчеләр исәпләвенчә, алар ярты тонна "шайтан төнәтмәсе" әзерләргә җыенганнар.

Татарстан буенча бу елның беренче кварталы эчендә барлыгы 60 килограмм наркотик табылган, 431 җинаятьче кулга алынган һәм республикага "шайтан төнәтмәсе" агызып торган 8 канал ябылган. Әйтергә кирәк, соңгылары наркотикларга каршы көрәшүчеләр өчен аеруча катлаулы мәсьәлә булып тора. Чөнки товарны ташучылар аны бик оста итеп яшерә беләләр. Күптән түгел М17 трассасында дәваланырга баручы колясĸада йөрүче инвалидның машинасын туктатканнар. Автомобильне җентекләп тикшергәч, анда, медицина документларыннан башка, нишләптер 20 килограмм наркотик табыла. Инвалидка сәламәтлеген ныгыту турында онытырга туры киләчәк – тыелган йөкнең авырлыгы бөтен калган гомерне читлек артында уздыруга тарта. Тагын бер Казан "уйлап чыгаручысы" криминаль товарны... мармелад аю балалары формасында тәкъдим иткән. Өендә киндер плантациясе үстереп, ул аннан исерткеч матдә чыгарган һәм, аны желатин белән кушып, формаларга агызып катырган. Нәтиҗәсе шул ук – мармелад плантаторы рәшәткә артына озатылган.

Шул ук Казанда, Бауман урамында... чебен гөмбәсе белән сәүдә итүче ир кешене тоткарлаганнар. Сәүдәгәр кызыксынучыларга оста итеп аны ризыкка өстәмә итеп файдаланырга тәкъдим иткән. Имеш, ул организм эшчәнлегенә активлык өсти икән. Моның ничек эшләнүен ул аңлатып тормаган – чебен гөмбәсе актив рәвештә зиһенне чуалта һәм галлюцинациягә китерә.


Гади кешеләрнең ак үлем белән сәүдә итеп баерга теләүләрен белдек ди, ә менә РФның атказанган артисткасы Рәмилә Искәндәрнең хокук сакчылары кулына эләгүен аңлау бик кыен. Дистәләгән фильмнарда уйнаган актрисаның тормыштагы уены тискәре роль булып чыккан. Аның өендә сату өчен әзерләп куелган наркотиклы төргәкләр табылган. Сәнгатьтән бик ерак торган "эшчәнлеге" өчен ул алты ел колония алган.

Наркотиклар безнең шәһәр-авылларыбызда тарала тора. Кызганыч, бу агуны кабул итеп онытылырга теләүчеләрнең саны кимеми. Ә безнең тормышыбызга интернет керү белән "җан дәвасын" табу һич тә кыен түгел. Бу проблеманы ничек хәл итәргә икәнен әлегә беркем дә белми. Бер нәрсә генә ачык – наркобароннар да, курьерлар да, аларның клиентлары да озак яшәми: берәүләр – иректә, икенчеләр – бу дөньяда. Иртәме, соңмы, бөтенесе дә ак үлемне кулланудан туктый, ләкин сирәкләре генә – исән чакта.

Людмила САФИУЛЛИНА













• • •

– Сезгә нәрсә белән булса да ярдәм итәргә яки киңәш белән булыша аламмы?

– Әйе, әйтегезче, зинһар, сезнең кибетнең кайсы төшендә видеокамералар куелмаган?

• • •

Кая анда ашкынып чапкан вакытта атны туктату... Кайбер рус мегаполисында бар шундый ханымнар – чак кына, кискен итеп рульләрен борып йөзәр машина өйгәннәре...

• • •

– СССРда тимер-томыр һәм кәгазь җыюны пионерлар башкарган, ә хәзер аны бомжлар үти.

– Шулар бит инде алар... Үсеп җиткәннәр!

• • •

Сатучылар һәрвакыт бәя язуларын яңартып торалар. Сатып алучыларга да акчадагы саннарны үзгәртеп язарга рөхсәт бирсеннәр иде.

• • •

– Официант, ашымда итек олтаны, тәгәрмәч покрышкасының кисәге, бензин шулпасы, шешә бөкеләре!

– Бу аш диңгез продуктларыннан әзерләнгән, нәрсәләр топтык, шулардан пешердек.

• • •

– Безнең фирмада җенси яктан бернинди тигез хокуктан мәхрүм итү юк: барыбызга да бертөсле аз түлиләр.

• • •

– Улым, син тиздән мәктәпне тәмамларсың, инде үзеңә һөнәр сайлар вакыт. Әниең белән синең табиб булуыңны телибез.

– Син нәрсә, әти! Мин бит хәтта чебен үтерергә дә кызганам!

• • •

Бүген үзебезнең хатын-кызлар коллективында кем ничек, нәрсә ашатып яши ирләренә. Бер хезмәткәр ханым зур горурлык белән: "Үзебез нәрсә ашыйбыз, аңа да шуны бирәбез!" – дип әйтеп сала.

• • •

– Нинди югары уку йортында укыйсың?

– Төгәл белмим, ләкин әтием бик кыйммәтлесендә, ди.

• • •

Салкын һәм кайнар су счётчикларын тикшерү мондый нәтиҗәгә китергән: яшәүчеләр кайнар су белән кулланып кына калмыйлар, аны яңадан сууткәргеч торбага агызалар икән.



Абау!

КҮҢЕЛСЕЗ НӘТИҖӘ

Татарстанда "Фельдшер ярдәмчесе" проекты уңышсыз тәмамланды. Узган ел фельдшер-акушер пунктларында эшләү өчен меңнән артык медицинага мөнәсәбәте булмаган кеше әзерләнгән иде. Проектны тормышка ашыру өчен 750 миллион сум соралган булса, чынлыкта исә бары тик 15 миллион бүлеп бирелгән, ә өйрәнчек ярдәмчеләргә хезмәт хакын хастаханә хезмәткәрләренекеннән кисеп түләгәннәр. Нәтиҗәдә, беренче ярдәм дә күрсәтә белми торган секретарь һәм санитарка белгечлеге буенча фельдшер ярдәмчесе әзерләнгән.

БАЛАЛАР – ЧИТЛЕКТӘ

Статистика күрсәткечләре буенча, республикада балалар җинаятьчелеге арта. Дүрт ай эчендә балигъ булмаганнар катнашы белән 258 җинаять эше каралган. 183 яшүсмер закон бозган: 17се исерек хәлдә булган, 16 сы судта беренче тапкыр гына түгел, ә 45 е беркайда да укымый һәм эшләми. Узган ел белән чагыштырганда, яшь буын бу өлкәдә алга киткән – автомобиль урлаулар 5 тән 23 очракка, мошенниклык 26 дан 35 кә, наркотиклар тарату 43 тән 71 гә кадәр арткан.


ТЕЛЕФОН КАРАКЛАРЫ

Һәр көн саен Татарстан халкыннан мошенниклар 10–15 миллион сум (!) урлыйлар. Моңа җыелган акчалар гына түгел, ә ялган юл белән алынган кредитлар да керә. Россия буенча тәүлегенә барлыгы 20 миллион шалтырату исәпләнә. Ә урланган акчаларның күләме узган ел эчендә 250 миллиард сум тәшкил иткән. Украинада гына 400 гә кадәр мошенниклык үзәге эшли. "Табыш"ларның 40 проценты Украина армиясен финанслауга бара.

ХӘМЕРЛЕ ЯЛ

Чаллыда яшәүче берәү больничныйга еш йөргән өчен суд каршына басачак. Ир кеше хәмер белән бик дус булган, ә эшен югалтырга теләмәгән. Эшеннән колак какмас өчен, ул больничныйлар сатып алган. Табибларга акчаны таныш шәфкать туташы аша тапшырып барган. Мавыгуы өчен хәмер сөюче акча җәлләмәгән – "шәраб бәйрәмнәренең" дәвамлыгына карап, ялган документлар өчен 1,2 дән 3,5 мең сумга кадәр түләгән. Җаваплылыкка "яшел елан" дусты гына түгел, биш медицина хезмәткәре дә тартылачак.







СӘРХУШ ЕЛМАЮ-ЛАР

•••

Бер ир – икенчесенә:

– Мин һәрвакыт, алай-болай артыгын җибәрсәм, өйгә кайтарып куйсыннар дип, кесәмә адресым язылган кәгазь тыгып куям.

– Анда нәрсә язасың соң?

– Мәскәү. Кутузов проспекты.

– Соң син бит Чиләбедә яшисең!

– Әйе, Чиләбедә. Тик шулай да берничә тапкыр Мәскәүгә илтеп ташлаганнары булды!

•••

Урам буйлап ике сәрхуш бара һәм берсе икенчесенә болай ди:

– Әйдә, бер яртыга бәхәсләшәбез: өйгә кайтып кергәч тә хатынымның беренче сүзе «җаным» булачак.

– Син үзеңә кара – исерек, пычрак...

– Бәхәсләшәбез!

– Беләм мин синең хатыныңны – аннан да усалны табып булмый...

– Бәхәсләшәбез!!!

– Ярый, бәхәсләшәбез.

Моның өенә кайтып керәләр.

– Җаным, зинһар, ишекне ач әле.

– Җаным?!!! Кайчан шул аракыдан аягыңны сузарсың икән, бәдбәхет!

•••

– Әти, исерек ул нинди була?

– Улым, менә шушы ике агачны күрәсеңме? Ә исереккә алар дүртәү булып тоела. Аңладыңмы?

– Әйе, әти. Ләкин монда бер генә агач бит.

Александр БРЮХАНОВ

БЕР ИР ЭЧКӘЧ БОЛАЙ БУЛГАН...

Менә мин сезгә болай дип әйтәм: хатын-кыз булган җирдә, гомумән, күп эчәргә ярамый. Кунакка баргач бер ир хатынын үбәм дип, башка хатыннарны үбә башлый, барысын да үбеп бетермичә, үз хатыны янына көчкә барып җиткән, әле танымый да тора ди. Нәтиҗәдә, башына салат савыты белән органнар.

Икенче берәү кичәдә бераз шәраб капкан да җебебрәп киткән һәм зур гына гәүдәле, таза, йомшак хатынга башын куеп изрәп йокыга киткән. Мәрхәмәтле ханым, әлбәттә, аңа бернинди авыр сүз әйтмәгән. Шуннан соң бу ир аның фатирында батареяга беркетелгән килеш өч ай яшәгән. Йомшак табигатьле әлеге ханым аны обойларын ябыштыртмыйча, түшәмнәрен агартмыйча өенә кайтарып җибәрмәгән. Шуннан соң ирләр күп эчә торган җирләргә еш йөри икән шул хатын, сантехник эзли ди...

Тагын бер мондыйрак очрак булган. Бер ирнең корпоративларда үзе генә эчеп йөрүе җитмәгән, тагын ике хатынны да эчертә икән. Корпоратив тәмамлангач, үзе аеграк, ә теге ике хатын ычкынган, предохранитель сыман янганнар. Ике кулына ике хатынны күтәреп, кая барырга белмичә аптырап калган... Чөнки өендә дә бит әле ике хатын – хәләл җефете һәм тещасы уклау тотып көтеп торалар...

Ә бер ир шундый хатын белән танышкан, сүз ара сүз чыгып, эчәргә килешкәннәр һәм иртән уянып киткәч, үзен хатын-кыз буларак хис иткән. Әле хәзергә кадәр аңга килә алмый ди: әллә ярамаган аракы эчкән, әллә танышкан хатын – пластик хирург булган...


Аннан соң тагын бер очрак: ике ир яхшы гына кәеф-сафа корганнар, бик соңга хәтле утырганнар һәм берсе әйтә ди: «Әйдә киттек, мине бүген шундый хатыннар чакырды, тик менә шунысы кыенрак: тәрәзә аша керергә туры киләчәк, аларның тулай торагында каравылчы бик әшәке кеше икән. Киткәннәр, тәрәзәгә үрмәләп кергәннәр, тегендәге хатыннар белән бергәләп эчкәннәр. Озак кына күңел ачканнар, ныклабрак карасалар, бу венерология диспансеры булып чыккан... Әле хәзергә кадәр шуннан чыга алмыйлар ди.

Ә бер ир бернинди хатын-кызсыз эчкән һәм хатын-кыз затын күрергә дә, орынырга да өлгермичә, урамга чыгу белән ауган. Янына хатын-кызлар җыелган, үзара ирне кайсына алып керү турында гауга чыккан... Берсе бигрәк тә нык кыланган, ир шуның өлешенә тигән. Аның ЗАГСка чираты «яна» икән, булачак киявенең фамилиясе дә язылмаган. Инде шулар хәзер унбиш елга якын күгәрченнәр кебек гөр-гөр килеп яшәп яталар ди...


Менә шулай, бер карасаң, эчәргә ярамый; икенчедән, шул хатыннарга күз ташлавың була, эчмичә калу да килешми.

Алай да, эчмәскә тырышыгыз, ирләр, хатын-кызлар бит алар матурлар һәм нишләргә кирәген үзегез дә беләсез...





Валентин ДРУЖИНИН



Виталий ВЕСНИН

Элеккеге студент

Бервакыт безнең бүлеккә ике студент җибәргәннәр. Тәҗрибә тупларга. Болар үзләрен яхшы яктан таныттылар, әмма бер чатаклыклары килеп чыкты: алар совет кинематографиясе турында бернәрсә дә белмиләр икән, ә менә безнең җитәкчебез – Әмир Мәхмүтович, эш арасында һәрвакыт кинодан эләктергән цитаталар белән бик оста файдалана белә.

Шулай бер көнне бу егетләр төшке ял вакытыннан стаканлап тәкъдим ителгән капучино тотып кайттылар. Гади итеп кенә ясалган очсызлы кофе эчеп утыручы җитәкчебез, боларны күреп төшенке тавыш чыгарды:

– Халык өчен опиум ничә сум тора?

– Без наркотик белән кызыксынмыйбыз! – дип җавап бирде боларның берсе.

Аңышмыйча торган егетләрдән көлеп, аңлатырга керештем:

– Шеф сездән сорый – бер стаканы күпме торганын.

– Йөз илле, – диде егетләр.

– Безнең кешеләр ипи кибетенә таксида йөрмиләр! – дип җавап кайтарды шеф.

Егетләрнең берсе, сораулы караш ташлап, әйт әле бу ни дигәндәй, миңа карап катты.

– Мондый бәягә кофе эчү – студентларга артык кыйммәт рәхәтлек! – дип аңлаттым.

Җомга көнне егетләр алдагы көндә төнге клубка бару турында план кора башладылар. Җитәкчебез боларның сөйләшүенә үзенең өлешен кертте:

– Карагыз анда! Руссо туристо! Облико морале!

Егетләр, бер-берсенә карашып алдылар, күзләре миңа төбәлде:

– Анда үзегезне тәртипле тотыгыз, ди шеф – артык күп эчмәгез, кызларга бәйләнмәвегезне үтенә!

Шеф чыгып киткәч, егетләр миннән сорашырга тотындылар:

– Каян ала ул боларның барысын?

– Болар барысы да совет фильмнарында бар. Нәрсә, сез аларны караганыгыз юкмы әллә? – дип гаҗәпләндем мин дә.

– Карадык каравын! Ләкин кайбер фразаларны яттан отып калып сөйләүгә өйрәнмәдек – монысы артыкка китә!

Шулчак башыма мондый уй килде:

– Чамалагыз, цитаталарны белмәгән очракта шеф сезгә практикагыздан соң зачёт куймаска мөмкин!

– Ничек инде? – дип аптырап калдылар болар. – Безгә хәзер, берочтан бөтен фильмнарны карап чыгарга туры килә түгелме соң?

Шул вакыт шеф үзе пәйда булды:

– Ну, граждане алкоголики, хулиганы, тунеядцы... Кайсыгыз бүген эш күрсәтеп алырга тели?

Хәзер бишенче ярты бит инде! – дип шаулап алды егетләр. – Без бик күп эшләрне җайга керттек, ә сез безне ялкаулар дип атыйсыз...

– Шаяртам мин, шаяртам, – дип тынычландырды аларны Әмир Мәхмүтович. – Борчылмагыз!

Ә мин таләпчән тавыш белән:

– Хәзер сезгә ял көннәрендә нинди кинолар карарга икәнлеге турында исемлек язам!

Шефка бу турыда белдереп куйдым. Ул әлеге планны раслаганын белдерде.

Дүшәмбе көнне, эшкә килгәч егетләр сорады:

– Әмир Мәхмүтович, сез безнең практиканы яхшы үтүебезгә кул куярсызмы?

– Бәлки сезгә фатир ачкычын да бирергәдер һәм акчаның кайда ятканын да күрсәтергәдер? – диде шеф.

– "Двенадцать стульев!" – дип куйды, һич ялгышмый бер егет.

– Күрәсез, практикагыз файдага үткән! – дип шат тавыш белән әйтеп куйды шеф. – Нәрсә булса да өйрәнгәнегез бит! һәм өйрәттек тә!

Без инде бу хәлне күптән оныткан идек, шулай ике еллап вакыт үткәндер, кабинетка бер яшь кеше килеп керде:


– Мине сезгә эшкә җибәрделәр! – ди.

– Таныш йөз. Фамилиягез ничек? – дип сорады аннан җитәкче.

– Минем фамилия бик мәгълүм, әйтеп тормасам да була! – диде ул, һәм без әлеге рухи яктан ныгыган егеткә карап аның элеккеге егетләрнең берсе икәнен шундук таныдык.

ТИШЕК КӨПЧӘК

Виктор ФЁДОРОВ



ИДЕЛ БУЕНДАГЫ ҖӘҺӘННӘМ

Әйтегез әле, Боровое Матюшинода яшәүчеләрдән кем генә көнләшмәгән икән? Җырларда җырланган Идел яры, күккә кадәр сузылган чыршы-наратлар, борынгы стильдә салынган затлы сарайлар, елга ярыннан сузылган шәхси пирслар, әйләндереп алынган мәйданнар, ялтыравыклы автомобильләр... Ил милкенә хуҗа булган байгуралар тормышының бөтен гүзәллеге! Мин дә беркөнне гаиләм белән эссе җәй көнендә Идел суында коенып, комда иркәләнеп ятарбыз дип, шул якка юлга чыкканчы, бу оҗмахка тиң урынга сокланып карый идем. Әмма монда күргәннәрем татлы хыялларымны чәлпәрәмә китерде һәм "җәһәннәм тишеге" дигән сүзгә кайтып калды!

Ял көннәрендә мондагы кечкенә генә пляжга ярты Казан чыга торгандыр, мөгаен. Һәм барысы да машинада. Байлар бистәсен тар гына асфальтлы юл кисеп үтә. Мондагы хәлне күз алдына китерү кыен түгел: юл буенча тәртипсез рәвештә тезелгән автомобильләр аны тар сукмакка әверелдерә, хәрәкәт ике юнәлештә дә туктап кала, машиналар арасында халык бөтерелә, шау-шу, сүгенү кайчагында йодрык уйнатуга барып җитә...


Мәсәлән, 12 июньдә 30 градуслы эсседә машиналар "бөке"се Боровое Матюшино борылышыннан Якты Аланга кадәр диярлек сузылган иде. Һәм мондый хәл ел саен ял көннәрендә кабатлана, дип сөйлиләр. Кереп тә, чыгып та булмый! Һәм затлы джиплар эчендә иза чигүче монда яшәүче байгуралардан көнләшү түгел, аларны җәллисе генә кала.

Бу манзараны күзәткәннән соң башта (һәм минекендә генә түгелдер) бер фикер туа: "Әгәр болар үз йортларында да тәртип урнаштыра алмыйлар икән, алардан нәрсә көтәргә була инде..."

Ю. ШАРАЕВА

КАЗАН

Александр ШУЛЬПИНОВ





Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Нәрсә зыянлырак?

– Исәнмесез! Нәрсә борчый сезне? – дип кызыксынды табиб, бүлмәсенә кергәч.

– Сезгә сорауларым бар иде. Нәрсәдән башлыйм икән?

– Алай күп булгач, кайсыннан башласагыз да була, – диде табиб бераз елмаеп.

– Менә нәрсәне беләсем килә: миңа ярманың кайсын ашарга ярый?

– Ничек инде, кайсын? Кайсын яратасыз – шунысын ашагыз, – диде табиб, аптырабрак калып.

– Юк шул, Интернетта язалар бит: "Зыяны бар, табиб белән киңәшегез!" дип, шуңа күрә нинди ярма ашарга да белгән юк.

– Хм... – дип, табиб уйга батты. – Ярманың барысы да файдалы. Сез бит көн саен бер ризык ашамыйсыздыр?

– Юк ла, шуңа кызыксынам.

– Алай булгач, барысын да ашарга ярый. Курыкмыйча ашагыз. Тагын нинди сорау?

– Яшелчәнең кайсын ашарга ярый?

– Бөтенесен рәхәтләнеп ашагыз!

– Ә менә интернетта язылган: "Зыяны күп, табиб белән киңәшергә кирәк", дип.

– Яшелчәнең бөтенесе файдалы, ниндиен ашасагыз да була. Инде беттеме?

– Юк, тагын соравым бар...

– Бу юлы нәрсә?

– Җиләк-җимешнең кайсысы файдалы, кайсысы зыянлы?

– Нормасын белебрәк ашасагыз, файдалырак икәнен исегездә тотыгыз! Зыянлы дип язылганмы интернетта?

– Әйе шул. Хәзер нәрсә ашарга белмәссең. Ите дә зыянлы, ярмасы да... Барысы турында табиб белән киңәшергә тәкъдим ителә.

– Әһә... Димәк, интернетта еш утырасыз. Йокыгыз да качкандыр?

– Йокы турында күптән онытылды инде. Бар нәрсәне карап чыкканчы таң ата. Блогерлар төрле киңәш бирә. Бусы ярый, бусы ярамый. Баш каткан.

– Алай булгач, сезгә менә нәрсә киңәш итәр идем. Интернетта күп утырмагыз. Йокыгыз да рәтләнер. Әлегә бер дару язам. Йоклар алдыннан эчәрсез!

– Рәхмәт яусын, – дип сөенеп, чыгып киттем.

Юлда даруханәгә кереп, табиб язган кәгазьне сузам.

– Ул дару бездә юк әлегә, – диде чибәр кыз. – Аның урынына икенче дару тәкъдим итә алабыз. Аннан, безнең бүген күп даруларга акция. Арзан бәяләргә алып була.

– Табиб белән киңәшәсе түгелме?

– Юк. Бәясе арзан вакытта алып калыгыз.

Үгетләүләренә һәм акциягә игътибар итмичә, булмаган дару урынына кирәген генә алдым.

Өйгә кайтып укысам, берәр зарары юк микән дип. Язылган: "Файдасына караганда зыяны күбрәк икән: аллергия реакциясе булырга мөмкин, эч авырту, баш әйләнү, йоклый алмау, күз күреме начараю, кома, клиник үлем..."

Менә шуннан соң исән калып карагыз, дусларым!

* * *

– Доктор, зинһар өчен, ярдәм итегез. Мин үземне күбәләк итеп тоям.

– Алайса сезгә миңа түгел, ә психиатрга мөрәҗәгать итәргә кирәк.

– Мин аңа бара идем дә инде, ләкин тәрәзәгездә ут күрдем.

* * *

Пациент – теш табибына:

– Нишлисез сез? Сәламәт тешне суырдыгыз бит!

– Ашыкмагыз! Әкренләп авыру тешегезгә дә барып җитәрмен!







• • •

Нәни малай велосипедына атлана, руленә чиртеп куя һәм тик кенә утыра.

Әнисе:

– Нишләп утырасың?

– Җылынганын көтәм.

• • •

– Син нинди рәсем ясыйсың?

– Фатир ясыйм.

– Безнекенме?

– Юк, булырга тиешлесен.

• • •

Әнисе – нәниенә:

– Менә синең курчагың, кочакла да йокла.

– Әни, ә бүген минем белән берәр тере зат йоклыймы?

• • •

Әтисе улын балалар бакчасыннан ала.

– Нәрсә, бүген беркем белән дә сугышмадыңмы?

– Юк, бер малайга озак итеп сдача бирдем...

• • •

Балалар хастаханәсендә улы сорый:

– Әни нигә монда Айболит ясап куелган? Ул хайваннарны дәвалаган ич!

• • •

– Егетләр алар туңдырма алып бирә һәм үбешә, – дип сөйләнә нәни кыз. – Ә ир– ул өйдә шүрлек кагучы һәм ашаучы.

• • •

– Әни, ә әти нигә кирәк?

– Әтиме? Яшәр өчен.

– Ә әни – яшәү күңелсез булмасын өченме?

• • •

– Әти, ремонт беткәндә миңа ничә яшь булачак?

• • •

Сүз тыңламаучы баласына – әнисе:

– Без сине иркәләп бетердек бугай... Җәза бирә башларга вакыт!

– Ничек инде? Сез иркәләгәнсез, ә җәзасы миңамы!

• • •

– Әни, йөзүгә йөрү миңа ник кирәк? Мин теләмим!

– Көчле, матур булырсың бөтен кызлар артыңнан чабып йөриячәк.

– Чапсынар – мин аларны барыбер узып китәчәкмен.

• • •

– Кызым, иң яраткан әйберләрең нәрсә?


– Туңдырма һәм лимонад.

– Кешеләр арасыннан?

– Ә мин кешеләрне ашамыйм.



Михаил ЛАРИЧЕВ







Абау!

КНОПКАГА БАСЫП

Бер оборона предприетиесенең элеккеге хезмәткәре гаепләнүчеләр эскәмиясенә эләккән. Ул «Россия Федерациясенең критик мәгълүмат инфраструктурасына законсыз йогынты ясауда» гаепләнә. Эштән киткәндә, ул эш компьютерыннан «Чүп» папкасын бетергән. Гаепләнүче сүзләре буенча, ул шәхси мәгълүматлардан һәм компаниянең күчермәләре булган сызым проектларыннан котылган. Әмма куркынычсызлык хезмәткәрләренең карашы башка: төймәгә бер тапкыр басып, ул бер терабайт рәсми мәгълүматны юкка чыгарган һәм дәүләт заказын бозган диярлек. Өстәл җыештырган өчен пөхтә хезмәткәргә 8 ел төрмә яный.

КҮРЕНМИ ТОРГАН АДМИНИСТРАЦИЯ

Мәскәү өлкәсендәге Химки шәһәрендә яңа истәлекле урын барлыкка килгән – җирле хакимият бинасы яңа көзге коймa белән әйләндереп алынган. Алар аңлатуынча, мондый футуристик чишелеш паркны тышкы яктан чагылдыру өчен, мәйданны визуаль яктан киңәйтү өчен сайланган. Ләкин сәнгать объекты күп кешегә ошап бетмәгән. Кайберәүләр күренми торган коймa куркыныч дип саныйлар – очраклы рәвештә аңа бәрелү мөмкин, икенчеләре чиновниклар үзләрен халыктан качырган дип уйлый.

СКОТЧ

Волгоградта, Тулака микрорайонында подрядчик җәяүлеләр күперендәге ватыкларны скотч ярдәмендә ремонтлаган. Шәһәр кешеләре чишелешнең гадилегенә шулкадәр гаҗәпләнгәннәр, хәтта ачуланмаганнар да, киләчәктә изолента кулланырга киңәш иткәннәр. Ул ышанычлырак.

ЮК-БАРГА ЫШАНУЧЫ

Мәскәү янындагы Егорьевск шәһәрендә наркотиклар сатучы ... хорафатлар аркасында гаделлеккә хөкемгә бирелгән. Бакчачылык җәмгыятьләренең берсендә ул 667 нче номерлы участокта наркотик лабораториясе булдырган. Ләкин наркотикны ясау барышында участок номеры 666 икәне ачыкланган. Ир кеше җанвар саннарын югарыдан билге дип уйлап, үз ризалыгы белән бирелергә киткән.









ЧЫН ХАЛЫК ЯЗУЧЫСЫ

Камил Кәримовка халык язучысы дигән ифрат та абруйлы исем бирелү уңаеннан сөенечле хәбәр ишетү без – "Чаян" журналы редакциясе хезмәткәрләренә аеруча шатлык өстәде.

Әйе, мин аның якын дусты буларак, әллә нинди мактау сүзләре яза алыр идем. Чөнки ул – иҗаттәш, сәхнәдәш, фикердәш. Бәйләнешебез шактый байтак еллар буе дәвам итте – хәзер дә шулай. Камилнең чын халык язучысы икәнлегенә басым ясап, сырланып, мактап тору кирәк тә түгел, ул аны бар булганы белән халкыбызга хезмәт итеп алган, дәресрәге – белеп, танып бирганнәр.

Бу нисбәттән шуны әйтәсем килә: хәзерге халык язучылары, шагыйрьләре, әлеге мактаулы исемгә лаек булу белән (кайберәүләре) матбугатка язудан шып туктыйлар. Әйе, аларга хөкүмәтебез өстәмә түләү шартлары тудырган. Иҗат итүдән туктату өчен түгел бит инде мондый хәл, минем уйлавым буенча, киресенчә, аларны иҗатка ныграк рухландыру максатыннан эшләнгән күркәм гамәлдер дип уйлыйм. Ә бит, элегрәк классик язучыларыбыз (һәммәсе дә) "Чаян" журналында фельетон жанрлары, шигырьләре, эпиграммалары белән актив катнашканнар. Бер сүз белән әйткәндә: зур эшчәнлек күрсәткәннәр. Минемчә, халык язучысы булу өчен киң масштабта фикер йөртергә һәм халкыңның карашында, уенда булырга тиешсең. Мондый сыйфатларга тиң рәвештә Камил дустыбыз, "Чаян" журналында 15 ел хезмәт куйган, "Казан утлары"нда иҗатын, редакторлык сәләтен чарлаган, романнары белән халык мәхәббәтен казанган. Санап бетерерлек түгел аның риясыз хезмәт куйган матур гамәлләре. Шуңа күрә мактаулы исем бирелүе дә бик урынлы! Озын, озак иҗади тормыш һәм саулык теләп калабыз!

Алмаз ХӘМЗИН

Игорь КИЙКО



САБАНТУЙ ГЫЙБРӘТЛӘРЕ

Илдә Сабантуйлары гөрли. Инде алдан ук кайда, кайчан үткәреләчәге аерым карарлар белән билгеләнеп куелган иде.

Мәсәлән, Бурсыклар илендә июньнең беренче атнасы ял көнендә, Бүреләрдә – икенче атнадагы ялда, ә Төлкеләрдә – өченчесендә. Атларныкы – ай ахырындагы көннәрнең ялында. Шулай, җәнлек вә хайван халкы эшләп димме, яшәпме арыгач – бәйрәм кирәк! Ашаласы – ашалган, урланасы – урланган, таланасы – таланган, бүленәсе – бүленгән. Артыгы читкә яшерелгән: кодаларга, балаларга язылган – акчалата, җирләтә, мөлкәтләтә. Тантаналар уздырасы гына калган, ягъни Сабантуйлар! Сыерлар, сарык-кәҗәләр-тәкәләр, бозаулар, бәтиләр мәш килә. Кортлар безелди, чыпчыклар чыркылдый, сандугачлар сайрый. Күктә тургай – кыр җырчысы – атказанганнарның алыштыргысыз сандугачы.

Инде Сабан туеның иң кәттәсе – барлык урман өлкәләренең уртак җыелма тантанасы көне бара. Табигатьнең иң гүзәл урыны сайлап алынган моңа. Урман халкының чуты юк икән. Әнә, чит-ят урманнардан да, дала-чүлләрдән дә, таулы, утраулы кыйтгалардан да вәкилләр килгән. Маймыллар да агач башында, филләр, арыслан-юлбарыслар, шакаллар, жирафлар, бегемотлар – берсе дә калмаган – барысы чакырылган.

Ниһаять фанфаралар яңгырап китте – башлана. Сабантуй-фест! Алан, төрле җәнлек рәсемнәре төшерелгән флаглар җилфердәве астында океан-диңгез тирбәлешенә әверелде. Мәйдан әле кызыл, әле зәңгәр, әле ал, сары, яшел, ак һәм аллы-гөлле йә күбек шар, йә хәтфә-келәмгә төрелде. Ярты сәгать буе күз явын ала торган тамаша, көчле алкышларга кушылып, офыкларга таралды.

Инде чират, күркәмлек төсе алып, күренекле хайван-җәнлекләрне бүләкләү тантанасына күчте. Бурсыклар иленең иң текә Бурсыгы, сүз алып, барлык куян, тиен, керпе халкын бәйрәм белән котлады һәм үзе кебек үк дәрәҗәгә ирешкән Бүре иле вожагының күкрәгенә Дуслык ордены такты. Шулай ук мондый бүләккә Төлкеләр мәмләкәтенең башлыгы да лаек ителде.

Сүзне Бүре җөмһүрияте вожагына бирделәр. Ул, үз чиратында, беренче итеп, Бурсыклар җитәкчесенә үз краеның иң зур бүләген күкрәгенә кадады, Төлкеләр урманы губернаторы да өлешсез калмады. Инде Төлке, хәйләкәр елмаюын яшермичә, Бурсык һәм Бүрене, кочаклый-кочаклый, үпкәндәй кыланды. Аңа киләсе ел Сабан туен уздыру максаты итеп кучмә кубок тапшырылды. И-и куандылар, и-и сөенештеләр инде үзләренчә.

Юкка түгел, бөтен дөньяда хәзер шундый гадәт!

Көннәр бик эссе торса да, ат чабышлары да үткәрелде. Нигә, алар башкалардан кимме әллә?.. Читтән генә үзем дә карап тордым – кылый күзле Куян кебек. Ул ярышта катнашсам, беренче киләчәгемә ышанмый идем. Чамасыз кызу бит һава... Әнә ярыштан төшеп калган атлар ничек атлый, мескеннәр. Янганнар түгелме соң?

Ишеткәнем булды: быел кайдадыр эш атларын чабыштырганнар икән. Арбасына цемент төяп, шушы эсседә. Берсе финишка килеп җитәрәк аягын сузган ди. Аңа цемент кирәк, ә аты җан биреп ята...

Күзгә ташланган гыйбрәтле хәлләр күп була ул Сабантуйларда. Уйланыгыз әле бераз, җәмәгать?!. Куян булып беттекме әллә инде? Ат хәленә калдыкмы?..

Фарсель ЗЫЯТДИНОВ

МИЛЛИОНЕР

Космос аша теләсә кайсы җисем белән сөйләшеп була торган әкәмәт телефон куелгач, иң беренче итеп әбекәйгә шалтыратырга булдым:


– Әлү-әлү! Оҗмахмы бу? Бик әйбәт, туры килеп торуын әйт әле син аның... Борчуым өчен кичерегез мине, шунда, якын-тирәдә, минем әбекәй күренмиме? Тәбәнәк кенә буйлы, йомшак тавышлы... бик игелекле... Исеме дисезме? Җирдә чакта Фатыйма диләр иде аңа... Хәзер дә шулаймы? Алайса, бик хуш, трубканы аңа бирегезче? Кәүсәр суы алырга китте? Нәрсә-нәрсә?! Судан кайтып киләме? Көтәм...

Шунда трубка шыгырдап куйды. Бераздан әбиемнең ягымлы, малай чактан ук күңелемә сеңеп калган йомшак тавышы ишетелде: "Бисмилләһир-рахмәнир-рахим. Әлү... тыңлыйм. Кем була соң әле бу?"

– Мин бу, – мин әйтәм, – синең оныгың. Әйе, әйе... Оҗмахта гына яшисең икән, әбекәй... Мин бик шат. Миңа да урын хәстәрли тор... күп яшисе калмагандыр инде, шәт... Яшь чакта җибәргән хаталарымны юып йөрим менә. Юкка борчый дип уйлама. Менә синнән дә гафу үтенергә булдым. Шук идем шул. Гафу ит, әбекәй... Минем яшь чакларны хәтерлисеңдер... Бервакыт шулай миңа унлык акча тоттырдың. "Илле тиененә ярты кило кәнфит ал да калганын кайтарып бирерсең", – дидең бит, үзең беләсең, барысын туздырып бетердем... Калганына түбән очтагы дус малайның иске сәгатен алып кайттым. Әй, ачуланган да идең шунда, әбекәй. "Беркайчан да акча тормас миндә, тормыш итә алмассың", – дидең. Ә мин гафу үтенәсе урында, үзең беләсең инде, күркә кебек кабарып киттем: "Акчамы? Тормас менә, миллионер булмасам, күрерсең менә", – дидем. Фәрештәнең "амин" дигән чагына туры килеп торуын әйт әле син аның, ә. Бүген шалтыратуымның да сәбәбе шул: тәки миллионер булдым бит, әбекәй... Ышанмыйсыңмы? Ипи тотып ант итәм, әбекәй: мин миллионер бүген... Оҗмахта яшим дисәм дә ярый... Тик түлисе бурычларымны кайтарып бирергә син генә юк янымда... Эх, әбекәй! Акчаны хәзер кая куеп бетерер хәл юк. Капчыклап ташыйм... Бер кисәк сабын, йөз грамм кәнфит алсам да, меңәрлекне генә ыргытып китәм... Саклап тот, дисеңме?! Әй әбекәй, акчаң күп булгач, нигә аны кызганырга! Таратам... Күккә ашканнарның рухы сөенсен, дим. Сәдаканы да сезнең вакыттагы кебек тиенләп түгел, ә меңәрләп бирәбез, әбекәй...


Ничек миллионер булдың, дисеңме?! Булыштылар, әбекәй... Көферләр игелекле хәзер. Шулар булышты. Бигрәк тә Борис дигән бабай белән Гайдар дигән агай булышты инде... Хәйдәр түгел лә, Гайдар, димен... Әйе, син аның әтисен беләсең... Язучы иде. Әби-бабайларга су китереп, утын ярып йөрүче Тимурчылар турында яза иде ул. Әйе, шуның малае. Тәмам баетып бетерде безне... Ничек дип соң? Рәсәйдә базар ясадылар... Базар булгач, акча булмыймы соң... Баюыбызга чыдый алмыйбыз... Әйтергә онытканмын икән: ирек алдык, әбекәй. Әйе, бирделәр... Ирекле эт кебек хәзер без.

Эх, син генә юк, әбекәй... Казаннардан Актанышларга кадәр таксиләрдә генә йөртер идем үзеңне... Әлү! Әлү! Әлү, дим... Кем өздә... Элемтә бүлеге? Миллион сумлык... Минме? Шулкадәрлек сөйләштемме? Булмаганны... Сез бит бар җыйган акчамны алып бетерәсез, болай булса. Ә мин әбекәйгә миллионер мин дип мактанган булам тагын...



Иосиф БОБРОВИЦКИЙ, 1960 ел.

Бер тагарактан.



Виктор ИГНАТЬЕВ, 1963 ел.

– Димәк, Джонни, Якын Көнчыгышта нәрсә үсә?
– Америкага каршы хәрәкәт!

Вячеслав ШИЛОВ



• • •

Башлангыч сыйныфларда укыганда әти-әниләре балалардан болай сорый:

– Нинди билге алдың?

Урта сыйныфларда:

– Өй эше күп бирделәрме?

Югары сыйныфларда:

– Мәктәптә булдыңмы?

• • •

Салым академиясе курсантларын иген урып-җыюына җибәргәннәр. Болар игенне хәтта җир астыннан да тапканнар! Мескенкәем, әле шытып чыгарга да өлгерми калган...

• • •

Журналист кыз редакция кушуы буенча стюардесса булып урнашкан. Беренче рейс. Самолёт командиры:

– Пассажирларга очып китәбез дип әйт.

Кыз:

– Сенсация! Безнең самолёт хәзер күккә очып китә!

• • •

Машина йөртүчеләр игътибарына! Әгәр машинада барасыз икән, сезне туктатып, ЮХИДИдан дисәләр, белегез – болар мошенниклар.

• • •

Әби:

– Оныкчыгым, бүген безгә бер яшь кенә кеше килде, шулхәтле озак итеп, аптекаларда безне ничек алдаганнарын сөйләде.

Оныгы:

– Ну син нинди прибор сатып алдың инде аннан?

• • •

– Менә, ял итәр өчен бакча сатып алдык.

– Ял итәсезме соң?

– Әйе, бакчага бармаган көнне...

• • •

Гаилә кыйммәтләре өчен көрәш дәүләтебезнең төп игътибарына әйләнде. Аның варислары бу көрәштә суд приставлары белән язмыш көйлиләр.

• • •

– Капчык белән йөгерү хәзер популяр спорт төренә әверелде.

– Нигә?

– Чөнки бүген миллионлаган яшьләр шундыйрак итеп киенеп йөри.

• • •

Суд ир белән хатынны аера:

– Нигә аерылышырга булдыгыз?

– Ул миңа чәчәкләр ыргыта.

– Күп хатын-кыз моңа шатланыр гына иде.

– Шулай, ләкин ул чәчәкләрне чүлмәгеннән дә өзеп тормый бит.





Александр АЛЁШИН



ҮРМӘЛӘП ЙӨРИБЕЗ

Хөрмәтле редакция! Уңайлы мохит – чамалы билгеләмә. Гадәттә ул, подъезд төбендәге пандус. Аның белән гарип кешеләр үз кирәкләре өчен яраклаша да алмый кайчакта, йә киңлеге туры килми, йә авышлыгы җайсыз. Ә бина эчендәге уңайсызлыклар турында әйтәсе дә юк, ул берәүне дә борчымый, күрәсең, иң мөһиме – тышкы тәртибен үтәү. Менә шәһәрнең күп кенә медицина оешмалары бу мәсьәләдә бигрәк тә нык калыша. Мисалга, Бутлеров урамындагы Республика офтальмологик клиника хастаханәсе. Барлык миңа кирәкле кабинетлар икенче катта урнашкан, лифт юк һәм булмаган да, өскә текә, тар агач баскыч менә. Икешәр таякка таянып йөрүче кешегә мондый биеклекне яулау Эверест түбәсенә менүгә тиңдер, үрмәләп менсәң генә инде. Шундый ук хәл Гагарин урамындагы 16 нчы хастаханәдә. Ортопед кабинеты, кем теләге беләндер, икенче катта. Монда менеп җитә алсаң, ялгыш кына икенче гариплек алырга да күп калмый. Инвалидларга бит зур игътибар кирәк, шунысын онытмаска иде.

Г. НӘБИУЛЛИНА

КАЗАН

ИМӘНЛЕКТӘГЕ ХӘЛЛӘР

Кадерле "Чаян!" Казандагы күп хәсрәтләр кичерүче торак комплексларына һәрвакыт нәрсә булса да җитешми. Кайсында мәктәп юк, балалар бакчасы кайда – җәмәгать транспорты. Ә безне "Имәнлек" торак комплексында светофорлар белән кимсетәләр һәм юлдагы полиция күпертмәләрен сай ясап интектерәләр. Аларның булмавыннан бик еш машина тәгәрмәче астына зурлар да балалар да эләгә. "Зебра"лар бар барын, әмма машина йөртүчеләр аңа игътибар итеп тормыйлар. Җәяүлеләр өчен урам аша чыгу урыннарында бар ул "полицияләр", ләкин "корсак"лары бәләкәй. Менә шундый эшләнеп бетмәгән юл кичүләре мәктәпләргә, балалар бакчаларына алып чыга. Андый учреждениеләргә башка юллар юк. Бу зарларыбызны инде җиде еллап төрле инстанцияләргә әйтеп яздык. Җавап бер – проблема бар, ләкин акча каралмаган. Түрәләр әлеге үтенечне канәгатьләндергәнче, инде тагын бер баланы бәреп киттеләр.

"Имәнлек" Т.К.та яшәүчеләр.

КАЗАН

Игорь КИЙКО





Вячеслав ШИЛОВ



Шагыйрь һәм прозаик Фаил Хафиз улы Шәфигуллин 1939 елның 18 маенда Татарстан АССРның Норлат (хәзерге Яшел Үзән) районы Карашәм авылында туа. 1953 елда җидееллык мәктәпне тәмамлагач, хезмәт юлын башлый: өч ел колхозда эшли, аннан Коми АССРда – урман кисүче, чирәм җирләрдә – тракторчы, Приморье краенда – кара эшче, слесарь, Тын океанның балык тоту флотында матрос була. 1962 елда ул туган якларына кайта һәм 1970 елның көзенә кадәр Яшел Үзән шәһәрендә заводта эшли. Аннары кичке урта мәктәпне һәм 1973 елда читтән торып Казан дәүләт университетының журналистика факультетын тәмамлый. 1969 елдан СССР Язучылар союзы члены.

1970 елдан башлап Фаил Шәфигуллин Казанда журналистика эшендә: башта «Казан утлары» журналы редакциясендә, аннары «Идел» әдәби альманахында хезмәт итә. Гомеренең соңгы елларында (1975–1982) ул республика юмор-сатира журналы «Чаян» редакциясендә әдәбият һәм тәрҗемә бүлеге мөдире булып эшләде.

Фаил Шәфигуллинның беренче шигырьләре көндәлек матбугатта 1958 елда күренә башлый. Шул беренче шигырьләрендә үк ул татар поэзиясенә үзенчә аһәң белән килүен, халыкның шигъри телендәге гади, табигый үзенчәлекләрне иҗади төстә куллана белүен ачык сиздерә. Шагыйрьнең «Яңа ел бусагасында», «Гашыйк», «Дулкынга дулкын» исемле җыентыклары әдәби җәмәгатьчелектә уңай бәя ала. Шулай да Фаил Шәфигуллин, шигъри иҗатын дәвам иткән хәлдә, 1960 нчы елларның ахырыннан башлап үзенең төп игътибарын проза жанрына, бигрәк тә аның юмор-сатира төренә һәм яшьләр-балалар әдәбиятына юнәлтә. Әдипнең шигъри хис, халыкчан рух, тормыш чынлыгы белән сугарылган, татар теленең нечкәлекләрен, нәфислеген тоеп язган күпсанлы хикәяләре һәм повестьлары җитмешенче еллардагы татар балалар прозасының һәм юмор-сатира жанрының үзенчәлекле бер өлешен тәшкил итә.

Фаил Шәфигуллин, актив иҗат тормышы белән яшәп, күптөрле җәмәгать эшләре алып барган язучы иде. Ул озак еллар буе «Казан утлары», «Чаян» журналларының һәм «Яшь ленинчы» газетасының редколлегия члены булып торды. Фаил Шәфигуллин иҗатының чәчәк аткан вакытында – 1982 елның 7 октябрендә фаҗигале рәвештә вафат булды.

НИГӘ КАЙТМЫЙ?

Моңа кадәр ишетелмәгән
Матур көйгә
Шәһәр буйлап тальян уйнап
Берәү килә.
Йокымсырап, изрәп торган
Таш биналар
Берәм-берәм сискәнешеп
Уяналар.
Иген шавын ияртеп килә
Гармун чыңы.
Сандугачлар озатып килә
Гармунчыны.
Асфальт буйлап ромашкалар,
Миләүшәләр
Матур көйне отыйк диеп
Йөгерешәләр...
Ә гармунчы басмакларга
Баса ныграк,
Җиз теллэрдән аһлар, зарлар
Чыга, сыкрап.
Ә гармунчы басмакларга
Һаман баса.
Үкси башлый тальян кинәт,
Гөлләр кача...
Тавыш килә язгы ерак
Ташулардан:
«Нәрсә җуйган бу гармунчы
Таш урамда?
Нигә кайтмый бу гармунчы
Басуларга?»

ТУЫП-ҮСКӘН НИГЕЗ ТАШЛАРЫНА

Меңәр яшьлек ташлар тып-тын ята,
Кычытканнар шашып чәчәк ата...
Ят бакчачы бага бакчаны.
Бар тирә-як чумган тирән моңга,
Ни өчендер тормыш сүнгән монда,
Кычытканнар җиңгән ташларны.

«Ничә еллар сезне иңебездә
Йөртсәк тә, юк рәхмәт сүзе безгә,
Апа, абый, сеңел, туташлар.
Калдырдыгыз ласа безне ятим,
Кычытканнар хәзер безгә хәким», –
Дияләрдер сыман бу ташлар.

Авыру аккошлар күк боек ташлар,
Кем ул әнә күзләрендә яшь бар,
Сезгә башын салып ник елый?..
Йөрәгендә лә сез кемнәрнеңдер,
Кемдер күрә сезне төшендә гел –
Туып-үскән нигез онытылмый.



АРЫШЛАР

Сәлимә ШӘМСИНА көе

Оныта алмыйм һаман,
Газапланам, янам,
Инде кайда гына йөрмәдем, –
Күңелемдә – арыш,
Сары сагыш, –
Башак шавын ишетәм төннәрен.

Үтсә җилләр исеп,
Шаулый диңгез кебек,
Офыкларга җитеп офыктан.
Күпме җырлар оттым,
Һәм оныттым,
Тик арышлар җырын онытмам.

Дулкынлана арыш,
Җанда таныш сагыш,
Көннәр инде көзгә авышкан.
Авылым кырларына
Мин һаман да
Сезне сагынып кайтам, арышлар.

ЯШЬЛЕГЕМ ТУГАЕ

Зиннур ГЫЙБАДУЛЛИН көе

Ничәнче мәртәбә
Нурланып яз килде,
Тургайлар канатын кагынды.
Күзләрең сагышлы,
Дип әйтте бер тургай,
Нишлим соң, тургаем, сагындым.

Ничәнче мәртәбә
Тургайлар килделәр.
Тугайлар яшәрде, ямьләнде.
Өздереп сайрады,
Сайрады бер тургай,
Читендер сагыну хәлләре.

Өздереп сайрама,
Хәлемне сорама –
Ул үзе аңлар бер, тургаем.
Минем күк сагынып,
Кайтыр ул, тургаем:
Онытмас яшьлеге тугаен.

ЫШАНМАГЫЗ, АВЫЛДАШЛАР

Ышанмагыз, авылдашлар:
Читтә тормыш яхшы, диләр,
Ышанмагыз, авылдашлар:
Кызыкмагыз, авылдашлар,
Киткәннәргә авылын ташлап.

Кайда да бер кояш, диләр,
Ышанмагыз, авылдашлар:
Безнең авыл өстендәге
Кояш якты бар кояштан.



Ринат НУРУЛЛИН

Апата һәм мода

Сез мине һич бүлдермәгез:
«Сөйләмә, – дип, – сафсата!»
Урманда төнлә йөрмәгез –
Анда яши апата.

Аның кутырлы корсагы
Яшелләнеп мүкләнгән.
Күкерт исе килеп торыр,
Якынрак килсә әгәр.

Юан муенында булыр
Әкәлидән муенса,
Агып торыр селәгәе
Шул муенса буенча.

Берәү генә түгел аның –
Өчәү очлы мөгезе.
Йөрәгең ярылыр, күрсәң –
Төнлә түгел – көндезен.

Апатаның кем икәнен
Кыскача сөйләп бирдем,
Тик алай да уй-максатым
Гел һич башкача иде.

...Ресторannan чыккан бер кыз,
Чәйни-чәйни сагызын.
Өенә кайтырга булган,
Машинасын кабызып.

Кузгалган. Бара икән бу
Көзгедән йөзен карап.
Соклана: матур буялган
Күз төбе – күксел-кара.

Күбәләк канат каккандай,
Керфекләре җилпенә.
Җилпәзәдән зуррак алар,
Утыртылган җилемгә.

Тырнаклары ис китәрлек,
Буялган гүя канга!
Ул тырнаклар озынрактыр
Апатаныкыннан да.

Күренә ки, кыз мөлаем,
Чибәр буласы килгән.
Соңгы модага ияреп,
Телен урталай телгән.

Борын яфрагын тиштереп,
Куйдырган металл ыргак.
Күкрәкләренә ярты пот
Силикон тутырттырган.

Иреннәрен кабарттырып,
Чыгарттырган ул алга,
Үрдәк борынына алар
Тулаем охшап калган...

Кайтып килә иде кебек
Югыйсә асфальт юлдан,
Ни хикмәттер, машинасы
Кызның урманга борган.

Машина ишеген ачкан,
Төшкән яшел чирәмгә.
Басып тора икән кызый,
Карап якын-тирәгә.

Апаталар кинәт чыгып
Өркетергә ярата:
Кинәт кызның күз явында
Пәйда булган апата.

Тик бу юлы апатаны
Сагалап торган каза;
Күрә пәри: каршысында
Тора куркыныч бер зат.

Имчәкләре шушы затның
Бегемотныкы кебек,
Томшыктагы тәмәкедән
Чыга куе төтене.

Апатабыз, кызны күргәч,
Коты очып егылган.
Гөрселдәп төшкән җиргә ул,
Хәтта тетрәгән урман.

...Кызның исән-сау урманнан
Кайтканын һәркем белә.
Апаталар юкка чыкты,
Калды бүреләр генә.

• • •

Бу хәл нигә китергәнен
Әйтеп бетерим инде:
Җеннәр белән ярышларда
Заман модасы җиңде.

Рөстәм ЗАРИПОВ

• • •

Бухгалтерың бармы? – дип сорыйлар,
Фирма ачыйм дисәң, ил-көндә...
Яхшы бухгалтерны табу кыен...
Полиция дә шул фикердә...

• • •

Танышканда канат куйды яры,
Купты давыл, күккә ашты күңел...
Өйләнешкәч мөгез куйды тагын
Һәм ул шуннан бирле мүкләк түгел...

• • •

«Мин сине яратам», дип белдерү –
«Сине генә сөям» түгел, дуслар...
Шул сүзгә алданып, кабаланып,
Яза күрмик һуштан...

• • •

Кибеттә рәтле йозак та,
Юк иде элек, иптәш...
Тимер ишекләр куелды
Демократия җиңгәч...

• • •

Кунакка дәштеләр, юлга чыктык,
Көн шыксызлыгына карамый...
Без килмәсәк, алар сөенәчәк,
Димәк, бармый калу ярамый...

• • •

Иске кием озаккарак чыдый,
Яңарагын сатып алмасаң...
Сукмәсәләр, җанга рәхәт була,
Йоклап калып, эшкә бармасаң...

• • •

Ак каенга сарыласың,
Нечкәргәндә күңелең...
Үткәннәрне сагынасың,
Хәртиләнсә күңелең...





ЧАЯН
САТИРА һӘМ
ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 7 (1944) июль 2024

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе
«ТАТМЕДИА»
акционерлык җәмгыяте.

420047, Татарстан Республикасы,
Казан, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм
коммуникацияләре агентлыгы
ярдәмендә оештырылган.
Журнал
Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы,
йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша
язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның
ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү
хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан,
Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.07.2024 ел.
Тираж – 2053 Заказ А-1448
**Редакциянең адресы: 420066,
Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.**
Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

Уйна да, уйла да!

ТРАНСПОРТ ЧАРАСЫ
... БАЛА
2
АРТИСТ ШӘҮКӘТ ...
"... НУР"
«СУТЫЙ»
ХАЙВАННЫҢ ТУНЫ
"... ЧӘЧӘГЕ"
6 июль — ... КӨНЕ
КЫЙММӘТЛЕ, СИРӘК ӘЙБЕР
САМОЛЁТ
...-МӘЗ
ТӨШСЕЗ ӨРЕК
4
АЛПАВЫТ БИЛӘМӘСЕ
"... ИСЕ"
АМЕРИКА ҮГЕЗЕ
ЗӘҢГӘР ЯГУЛЫК
"ИШЕТМӘСӘН – ..."
ЭШ АТЫ
... НУРИ
КУНАК БҮЛӘГЕ
11
"БЕР ТАУДА ... ЧИШМӘ"
... ТУКУ
... ШАКУ
ИШАРӘ
"...(-1), ИРКӘМ, ...(-1) ИНДЕ"
... БУ?
ДУС-...
"... ЧӘЧӘК"
5
УРТА АЗИЯДӘ "БАРД"
КОМПОЗИТОР ... ДАУТОВ
КӨНКҮРЕШ ЭЛЕКТР ПРИБОРЫ
6
"ИРЕН-НӘРЕН КЫЗЫЛ ..."
9
...-КАЗА
ЗУРАЙТКЫЧ ПЫЯЛА
10
4046,1 КВ. М
ЕРТКЫЧ КОШ
3
7
"...-ЕГЕТЛӘР"
КҮЛ-ЕЛГА ТӨБЕНДӘ УТЫРМА (-1)
ШАГЫЙРЬ ... БАЯН
"САРЫ ...(-1) САПЛАРЫ"
ӘТӘЧНЕҢ "ТАҖЫ"
РАХМАНКУЛОВА
8
ИКЕ ЮЛ КИСЕЛЕШЕ
12
ШӘКҮР ...
"АЛТЫН ..."
14
1
13



1. Совет музее әйберләрен һәм көнкүреш кирәк-яракларын кайдан табып була?

2. Эконом класста дөнья буйлап сәяхәт.

3. Җүләр акыллыдан нәрсәсе белән аерымлана?

4. Балалар тууны ничек арттырырга була?

5. Акыллы белән акылсыз кешеләр арасындагы аермалык нинди?

6. Иртәнге ашны чыгымлы итмәс өчен нишләргә кирәк?

7. Тупас белән ягымлы хатыннарның аермасы нәрсәдә?

ҖАВАПЛАР

1. Бакча йортларында һәм участокларында. 2. Глобус тирәли әйлән-бәйлән. 3. Җүләр башкалар алдында үзен акыллы итеп тотарга тырыша, ә акыллы, бөтәннәрдән аерылып тормас өчен, җүләргә сабыша. 4. Аның өчен интернетта песиләр фотосын түгел, ә үз балаларының фотоларын урнаштырырга кирәк. 5. Акыллылар ялгышлык ясамаска тырыша, ә җүләрләр – үзләренең ялгышларын танымаска. 6. Төшке аш вакыты җиткәч кенә уянырга. 7. Тупас хатыннар ирләрен үтмәс пычкы белән кисә, ә ягымлылары – лобзик ярдәмендә.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Ринат АБЗАЛОВ төзеде

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 6 нчы санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«ИРТӘНГЕ СЕРЕНАДА»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Чаллыдан


Гали БАҺАВЕТДИНОВ!


Әкияткә өстәмә

Валентин ДУБИНИН



Валерий ТАРАСЕНКО





Максим СМАГИН



Валентин ДРУЖИНИН